ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» 2009 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 4 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«14) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә башка нигезләр буенча профилактик исәптә торучыларга.»;

2) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«11. Җәмәгать тәрбиячесенең эше түбәндәге очракларда туктатыла:
1) балигъ булмаган зат 18 яшькә җиткәндә;
2) аны башка җәмәгать тәрбиячесе белән алыштырганда;
3) балигъ булмаган зат башка яшәү урынына күчеп киткәндә;
4) балигъ булмаган зат профилактик исәптән төшерелгәндә;
5) җәмәгать тәрбиячесенең, балигъ булмаганның яисә аның ата-анасының (аларны алыштыручы затларның) шәхси үтенече буенча;
6) әлеге Законда каралмаган башка очракларда балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе карары буенча.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 06 апрель
№ 26-ТРЗ